**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422643, д. Полянка,
ул. Механизаторов, дом 3б

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПОЛЯНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422643, Полянка авылы,
Механизаторлар урамы, 3б йорт,

**Тел.: (84361) 24002, Pol.Rs@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

16 ноябрь, 2021 ел Полянка ав. № 16

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Полянка авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Полянка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 8 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Полянка авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”гы 15 номерлы Карарын көчен югалткан дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Полянка авыл торак пунктында (Мелиорация урамы) үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Полянка авыл торак пунктында (Механизаторларурамы) үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Полянка авыл торак пунктында (Химиклар урамы) үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2021 елның 30 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Полянка авыл торак пунктында (Үзәк, Мәктәп, Яр буе урамнары) үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2021 елның 30 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

6.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Полянка авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга Сез ризамы?:

1. Полянка авылында урам утларын реконструкцияләү;
2. Полянка авылының урам юлларында чокырларны ремонтлау;
3. Кышкы чорда Полянка авылының урам юлларын карап тоту;
4. Җәйге чорда Полянка авылының урам юлларын карап тоту;
5. Полянка авылында контейнер мәйданчыкларытөзү;
6. Полянка авылында янгын гидрантлары урнаштыру һәм монтажлау;
7. Полянка авылындагы стойкалыюлбилгеләреналыштыру;
8. Полянка авылы өчен 6,5 км озынлыктагы сүүткәргеч челтәренең техник планын әзерләү буенча эшләр башкару

"ЯКЛАП" "КАРШЫ".

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Полянка авылы, Механизаторлар урамы, 3б йортһәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм шулай ук http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

8. Карар игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Полянка авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сираев